**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Африка дуңгыз чумасы белән чирләүне бетерү һәм чирнең таралуын кисәтү буенча эпизоотиягә каршы һәм профилактика чаралары үтәлү белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 37 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә:

а) эпизоотия чыганагында:

төньяк киңлекнең 55,1083 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 51,4207 градусы географик координатларыннан 5 км радиуста урнашкан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районындагы «Красновидово» аучылык хуҗалыгы территориясе чикләрендә;

б) куркыныч янаган зонада:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районының Петропавел Бистәсе авылы, Андреевка авылы, Аверьяновка авылы, Зирекле авылы, Бакташ авылы, Яңа Чишмә авылы, Татарстан Республикасы Әлмәт районының Яңа Троицкий авылы, Рокашево авылы, Шөгерчә авылы, Татарстан Республикасы Түбән Кама районының Благодатный авылы, Тау Иле авылы, Троицкий поселогы, Олы Сосновка авылы административ чикләрен кертеп, эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 5 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

в) күзәтчелек зонасында:

Татарстан Республикасы Азнакай, Аксубай, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Спас, Тукай, Теләче, Чирмешән, Чистай районнары административ чикләре кысаларында.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә 180 календарь көн дәвамында түбәндәге чикләүләр саклана:

дуңгызларны, 70ºС югарырак температурада аларны йогышсызландыруны тәэмин итә торган сәнәгать эшкәртүе узмаган дуңгызчылык продукциясен һәм аларны эшкәртүдән алынган продукцияне әлеге Указның 1 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән территорияләрдән транспортка төяп чыгаруны тыю;

әлеге Указның 1 пункты «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән территорияләрдә дуңгызларны сатуны тыю.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән тыюлар III һәм IV компартментларга караучы һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 37 номерлы боерыгы нигезендә расланган Африка дуңгыз чумасы белән чирләүне бетерү һәм чирнең таралуын кисәтүгә юнәлтелгән профилактика, диагностика, чикләү чараларын һәм башка чараларны тормышка ашыру, карантин һәм башка чикләүләр кертү һәм аларны бетерү буенча ветеринария кагыйдәләренең 38 пункты нигезендә күзәтчелек зонасыннан чыгарылган дуңгызчылык хуҗалыклары территорияләренә кагылмый.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлегә һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2021 елның 5 июлендәге ПУ-550 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 16 сентябрь
№ ПУ-721